**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№3589**
**27.05.2021**

Ел саен уздырыла торган «Сабан туе гүзәле – 2021» шәһәр конкурсын үткәрү турында

Башкарма комитетның 2019 елның 31 октябрендәге 5598 номерлы карары белән расланган 2020-2022 елларга Яр Чаллы шәһәрендә мәдәниятне үстерү муниципаль программасын үтәү йөзеннән, шәһәр яшьләре арасында татар милли мәдәниятен, йолаларны һәм гореф-гадәтләрне үстерү, саклау һәм пропагандалау кысаларында

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның мәдәният идарәсенә ел саен уздырыла торган «Сабан туе гүзәле – 2021» шәһәр конкурсын Яр Чаллы шәһәренең «Энергетик» мәдәният сарае» муниципаль автономияле мәдәният учреждениесендә 2021 елның 16 июнендә үткәрергә.

2. Расларга:

1) ел саен уздырыла торган «Сабан туе гүзәле – 2021» шәһәр конкурсын үткәрү турында нигезләмәне, 1 нче кушымтада каралганча;

2) ел саен уздырыла торган «Сабан туе гүзәле – 2021» шәһәр конкурсын әзерләү һәм үткәрү буенча оештыру комитеты составын, 2 нче кушымтада каралганча.

3. Башкарма комитетның финанс идарәсенә ел саен уздырыла торган «Сабан туе гүзәле – 2021» шәһәр конкурсын оештыру һәм үткәрү чыгымнарын финанслауны 2021 елга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетының «Мәдәният» 0801 бүлегендә (бүлекчәсендә) каралган акчалар хисабына 72 500 (җитмеш ике мең биш йөз) сум күләмендә, 3 нче кушымтада каралганча тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Р.М. Хәлимовка, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы С.Р. Мулюковага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2021 елның 27 маендагы
3589 нче карарына
1 нче кушымта

Ел саен уздырыла торган
«Сабан туе гүзәле – 2021» шәһәр конкурсын үткәрү турында
нигезләмә

1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1. Ел саен уздырыла торган «Сабан туе гүзәле – 2021» шәһәр конкурсы (алга таба – конкурс) Яр Чаллы шәһәре яшьләре арасында татар милли мәдәниятен, йолаларны һәм гореф-гадәтләрне үстерү, саклау һәм пропагандалау максатында үткәрелә.

2.Конкурсның төп бурычлары булып түбәндәгеләр тора:

1) яшьләрне милли мәдәнияткә җәлеп итү;

2) талантлы яшьләргә иҗади потенциалларын тормышка ашыруда ярдәм күрсәтү;

3) җәмгыять аңында кызларны гаиләдә дөрес тәрбияләүнең мөһимлеген формалаштыру;

4) татар халкының йолаларын һәм гореф-гадәтләрен саклау.

3. Конкурска әзерлекне һәм аны үткәрүне составы Башкарма комитет карары белән раслана торган оештыру комитеты (алга таба – оештыру комитеты) гамәлгә ашыра.

4. Оештыру комитетының төп функцияләре булып түбәндәгеләр тора:

1) конкурска әзерлек һәм аны үткәрү эшчәнлеген координацияләү;

2) конкурсны үткәрү, аның барышы һәм конкурсның йомгаклары турында нигезләмәне массакүләм мәгълүмат чаралары аша яктырту;

3) конкурсның жюри составын төзү.

2 бүлек. Конкурсны үткәрү тәртибе

5. Конкурста 16 яшьтән 25 яшькә кадәр, татар телен белгән, буй озынлыгы 162 сантиметрдан артык булган кызлар катнаша.

6. Конкурс ике турда үткәрелә:

1) сайлап алу туры – «Кызыл тау» мәдәният үзәге» МБМҮдә, Чулман проспекты, 119В йорты;

2) финал (конкурс финалистлары катнашындагы шоу программасы) – 2021 елның 16 июнендә 18.30 сәгатьтә «Энергетик» мәдәният сарае» МАМУда.

7. Сайлап алу турында катнашу өчен әлеге нигезләмәгә кушымтада каралган форма буенча заявка анкетасын һәм бөтен гәүдә белән төшкән фотографияне kzl.tau@mail.ru электрон адресы буенча җибәрергә кирәк.

8. Сайлап алу турына катнашучыларга түбәндәгеләрне әзерләргә кирәк:

1) визит карточкасы (үзе турында прозада, шигъри формада, театральләштерелгән сөйләү, видеоролик һ. б.) 2 минуттан артык түгел;

2) иҗади номер (вокал, хореография, театральләштерү, нәфис сүз, оригиналь жанр) 3 минуттан артык түгел.

9. Үзең белән алмаш аяк киеме, сәхнә костюмы, флеш-йөрткечтә фонограмма, фотография һәм сулыш органнарын шәхси саклау чарасы булырга тиеш.

10. Сайлап алу туры йомгаклары буенча жюри финалистларны билгели.

## 3 бүлек. Конкурсны йомгаклау

11. Чыгышларны бәяләү критерийлары:
1) татар телен белү;
2) сәхнә осталыгы;
3) сәхнә образы (костюм);
4) иҗади индивидуальлек.

12. Конкурста катнашучылар конкурс жюрие тарафыннан 10 баллы система буенча бәяләү критерийлары белән бәяләнә. Жюриның эш нәтиҗәләре беркетмә белән рәсмиләштерелә.

13. Иң күп бал җыючы катнашучылар конкурсның җиңүчеләре дип танылалар.

14) Призлы урыннар түбәндәге номинацияләр буенча бирелә:
1) «Иң шаян»;
2) «Иң тапкыр»;
3) «Иң заманча»;
4) «Иң үткен»;
5) «Иң иҗади»;
6) «Иң мөлаем»;
7) «Иң зифа»;
8) «Иң ягымлы»;
9) «Иң зәвыклы»;
10) «Иң нәзәкатьле».

15. Конкурс финалы җиңүчесенә «Сабан туе гүзәле – 2021» титулы бирелә.

16. Сайлап алу туры йомгаклары буенча өстәмә номинацияләр билгеләнергә мөмкин.

17. Конкурста катнашучылар бүләкләр, чәчәкләр бәйләме, дипломнар һәм хасите белән бүләкләнәләр.

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева

Ел саен уздырыла торган
«Сабан туе гүзәле – 2021»
шәһәр конкурсын үткәрү
турында нигезләмәгә
кушымта

«Сабан туе гүзәле – 2021» шәһәр конкурсында катнашучы
АНКЕТАСЫ

1. Ф.И.А.и.
2. Туган елы (тулы яшь).
3. Туган урыны (шәһәр, өлкә).
4. Адресы, телефоны, E-mail.
5. Паспорт мәгълүматлары.
6. ИНН.
7. Эшләгән, укыган урыны.
8. Хезмәт стажы.
9. Сезнең хобби.
10. Сезнең сәләтләрегез (кирәклесенең астына сызарга):

Сез җырлый, бии, юмористик өзекләр сөйли, музыка уен коралларында уйный беләсез.

11. Татар телен белү (кирәклесенең астына сызарга):

а) бик яхшы;
б) яхшы;
в) бик үк яхшы түгел;
г) начар.

12. Сезнең буй озынлыгы.